ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Законы аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану хакында» 48-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Р.У. Әхмәтов, О.М. Воронова, М.З. Гарифуллин, С.М. Захарова, А.С. Созинов, И.Г. Хәнипов, Р.А. Шиһабетдинов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Законы аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану хакында» 48-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 20 феврале
№ 209-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Р.У. Әхмәтов,
С.М. Захарова,
О.М. Воронова,
М.З. Гарифуллин,
А.С. Созинов,
И.Г. Хәнипов,
Р.А. Шиһабетдинов
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Законы аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш); 2024, № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.19 һәм 2.20 статьяларны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 8.1 статьяның 14 өлешендә «2.19 – 2.21» саннарын «2.21» саннарына алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан

Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 10; 2014, № 7; 2015, № 3, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш), «2.19 – 2.21» саннарын «2.21» саннарына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

«Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 6 һәм 7 пунктларын, $7^1$ һәм $7^2$ статьяларын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2013, № 10; 2015, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 95 (I өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

**4 статья**

«Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» 2022 елның 29 апрелендәге 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 34 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), «никотинлы продукцияне куллану өчен җайланмалар рекламасыннан,» сүзләреннән соң «потенциаль куркыныч булган көнкүреш билгеләнештәге газлы товарлардагы сыеклантырылган углеводород газларын һәм (яисә) аларның парларын сулау аша аларны куллануны пропагандалый йә күрсәтә торган мәгълүматтан,» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

**5 статья**

Әлеге Закон 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Законы аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы Законы проектына аңлатма**

Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасының аерым законнарын балигъ булмаганнарга алкогольсез тонусны күтәрә торган (шул исәптән энергетик) эчемлекләрне сатуны тыю билгеләнгән «Балигъ булмаганнарга алкогольсез тонусны күтәрә торган (шул исәптән энергетик) эчемлекләрне сатуны тыю турында һәм «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 8 августындагы 304-ФЗ номерлы Федераль законга (2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә), шулай ук балигъ булмаганнарга көнкүреш билгеләнештәге газлы товарларны сатуны тыю билгеләнгән «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 30 ноябрендәге 438-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында эшләнде.

Әлеге федераль законнардагы чикләүләрне бозу Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка китерә.

Шуңа бәйле рәвештә, шулай ук Татарстан Республикасы законнарында югарыда әйтелгән нигезләмәләрне кабатлауны бетерү максатларында түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

1) «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 6 һәм 7 пунктларын һәм $7^1$ һәм $7^2$ статьяларын үз көчен югалткан дип тану, алар нигезендә балигъ булмаганнарга алкогольсез тонусны күтәрә торган эчемлекләрне һәм гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен сыекландырылган углеводород газы кергән товарларны ваклап сату рөхсәт ителми, шулай ук балигъ булмаганнарны аларны куллануга җәлеп итү тыела;

2) әлеге чикләүләрне үтәмәгән өчен административ җаваплылык каралган Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.19 һәм 2.20 статьяларын үз көчен югалткан дип тану.

Моннан тыш, «Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» 2022 елның 29 апрелендәге 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына баланы потенциаль куркыныч булган көнкүреш билгеләнештәге газлы товарлардагы сыекландырылган углеводород газларын һәм (яисә) аларның парларын сулау аша аларны куллануны пропагандалый йә күрсәтә торган мәгълүматтан яклау хакындагы нигезләмә өстәү тәкъдим ителә.

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт

вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына төгәлләштерү характерындагы үзгәреш кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Законы аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Законы аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тану, туктатып тору, үзгәртү яисә кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Законы аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Законы аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.